СОВЕТ МАЛОЛЫЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ ЛЫЗИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ
13 июня 2023 г.

КАРАР
№83

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең депутатларга, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен җаваплылык чаралары күрү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

21.12.2021 елның 414-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законга, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге Уставына нигезләнеп Кече Лызи авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең 2020 елның 28 мае 233 нче номерлы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең депутатларга, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен җаваплылык чаралары күрү тәртибе» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3 пунктның 2 абзацында «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгының (Рәисенең)" сүзләренә алмаштырырга;

- 4 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе)" на алмаштырырга;

- 5 пунктның 2 абзацында «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгының (Рәисенең)" сүзләренә алмаштырырга;

- 6 пунктның 1 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе)" на алмаштырырга;

- 7 пунктның 1 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе)” на алмаштырырга;

- 7 пунктның 3 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе)” на алмаштырырга;

- 11 пунктның 1 абзацында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгына (Рәисенә)” алмаштырырга.

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы" нда бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Кече Лызи авыл җирлеге башлыгы А.С.Исмагилов